


12 нче февральдә Мордовиябезнен «Педагог 13.» нда татар шигъриятенә нигез салучы Һади Такташнын тууына 125 ел тулуга багышланган «Такташ укулары» тобәкара фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференциянен модераторы - этномәдәни белем бирv лабораториясе модире Елена Михайловна Наумова иде.

Катнашучыларга сәламләv сvзе белән «Педагог 13.ру» житәкчесе, педагогика фәннәре кандидаты, доцент, Мордовия Республикасынын атказанган мәгариф хезмәткәре Татьяна Васильевна Самсонова чыгыш ясады. Татьяна Васильевна билгеләп vткәнчә, Россия халыклары бердәмлеге елында әлеге конференцияне vткәрv аеруча актуаль. Һади Такташ vзенен әсәрләрендә кеше табигатенен универсаль темаларына кагыла, бу исә педагогларга укучыларда мәдәниятләрнен һәм телләрнен кvпторлелеген хөрмәт итәргә һәм анларга момкинлек бирә, һәр милләтнен кыйммәтен һәм анын гомуми Россия мәдәниятенә керткән олешен ассызыклый, ди.



Спикерлар һәм тынлаучылар сыйфатында туган телләр һәм әдәбият педагоглары, тарих укытучылары, китапханәләрнен методик-библиографик бvлекләре белгечләре, фән укытучылары, Мордовия Республикасы һәм Россия Федерациясе тобәкләре (Татарстан Республикасы, Пенза олкәсе) мәгариф оешмаларынын укыту-тәрбия эше буенча директор урынбасарлары – барлыгы 35 кеше катнашты.
Барыбызга да шатлыклы факт буларак шуны әйтәсе килә: яшь белгечләребез әлеге чараларда теләп катнашты. Шулай, якташ язучыбыз биографиясе һәм ижаты турында, балалар әдәбиятында Һади Такташ роле, укучыларга язучы турында белем биргәндә методик алымнар һәм башка темаларны яктыртып, Татарстан, Пенза олкәсе белгечләре белән бергә, А.С.Пушкин музее милли секторы белгече Ал-су Рашид кызы Тумпарованын «Мордовиядә туган язучыларыбыз» темасын як тырткан тирән мәгънәле чыгышы кызык

булды.

Татарстан Рес-публикасы Бугульма шәһәре 2нче лицее директоры урынбасары Гульнара Флурис кызы Нев-метулина «Татар балалар әдәбияты vсешендә Һади Такташнын роле», кvрше Пенза олкәсе Каменка районы Кикино урта мәктәбе татар теле һәм әдәбияты укытучысы Алмаз Рафаэль улы Акжегитов «Һади Такташ һәм анын ижаты» ту-рында тирән мәгълумат белән уртаклаштылар. Тагы татар теле һәм әдәбияты укытучылары – Ләмберә районы Татар Тавла топ мәктәбе Альфия Фатих кызы Муртазинанын, Рузаевка районы Татар Пеш-ләсеннән Сания Спартак кызы Саляеванын, Кадошкино районы Латышовка мәктәбеннән Светлана Равил кызы По-ташованын Хади Такташны мәктәптә ойрәнv темаларын яктыртып педагогик тәжрибәләре белән уртаклашу билгеләнгән иде.
Елена Михайловна Наумова «Такташ укулары» тобәкара фәнни-гамәли конференция се турында болай ди:
- ... «Такташ укулары» тобәкара фәнни-гамәли конференциясе эч-тәлекле vтте. Без максатыбызга ирештек: методик акцентлы элеге ди-станцион элементлы очрашу укытучыларыбыз хезмәтендә практик ярдәм булачак. Мин vзем әрзә милләтеннән булуыма карамастан, Торбеево районы Һади Такташ туган авылы Сыркыды музей-йортыннан Равилә Алим кызы Коновалова алып барган видео-сәяхәте бик кызыклы һәм киләчәктә куллану очен бай материал ишеттем. Торбеево районы китапханәсе белгече Елена Викторовна Кемешева эчтәлекле чыгышында якташыбыз турында китапханәдәге эш тәжрибәсе белән уртаклашты.

**Наилә НАСЫРОВА**